# КӨТӘМ СИНЕ

*САРА САДЫЙКОВА музыкасы*
*ӘХМӘТ ЕРИКӘЙ* сүзләре

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, көләч йөзле иркәм?
Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине һаман китәм, көтәм.

Сагыналар сине матур кошлар,
Сагыналар сине якын дуслар.
Күңелем эзли сине кич-иртән,
Мин сине һаман сагынып көтәм.

Китмисең минем йөрәгемнән,
Төшмисең минем телләремнән.
Көн саен, сәгать саен, иркәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм.

Кайт, иркәм, тизрәк — тизрәк миңа,
Синнән башка юк тормыш миңа.
«Көт, иркәм, кайтам», дигән сүзең
Музыка төсле тоела миңа.